Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының
Кәркәүч авыл җирлеге Советы

# КАРАР

22 сентябрь 2023 ел №17

Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 43 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 43 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында нигезләмәгә (2015 елның 15 июнендәге 27 номерлы , 2022 елның 15 июнендәге 14 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

16 нчы пунктның икенче абзацында «яисә алар тарафыннан тулы булмаган яисә дөрес булмаган мәгълүматлар бирү» дигән сүзләрне «үз чыгымнары турында белешмәләрне, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, белә торып тулы булмаган мәгълүматлар бирү, яисә белә торып дөрес булмаган мәгълүматлар бирү» дигән сүзләр белән алыштырырга, «яки хатынының

(иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында мәгълүматны тапшырмау яки белә торып тулы булмаган яки дөрес булмаган мәгълүмат тапшыру» сүзләрен «яки хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында мәгълүмат тапшырмау, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белә торып тулы булмаган мәгълүматлар бирү яки белә торып дөрес булмаган мәгълүматлар бирү» сүзләре белән алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Кәркәүч авыл
җирлеге башлыгы

М.Ф.Зәйнетдинов